Татарстан Республикасы Президенты Указы

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы һәм 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы Указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында нигезләмәгә, 10 пункттагы икенче абзацта «Татмедиа» Татарстан Республикасы массакүләм коммуникацияләр агентлыгы» сүзләрен «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм агентлыгы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы һәм 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы Указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2011 ел, 07 сентябрь
№ПУ-549